| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |
| 423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55. | | 423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт. |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 1 05.11.2020

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Әлем авыл җирлегенең Иске Әлем торак пунктында гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районы «Яңа Әлем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы, Яңа Әлем авыл җирлеге башлыгы:

КАРАР БИРӘ:

1.Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 16 ноябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда үзара салым түләүләренең бер тапкыр 18 яшькә җиткән һәр граждандан 500 (биш йөз) сум күләмендә кертелүенә, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә катнашуларына карамастан, алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 Төркем инвалидларыннан тыш, алар саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 процентган артмый торган 18 яшькә кадәрге гражданнардан 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне:

1. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Әлем, Иске Әлем авылларындагы юлларны карап тоту һәм ремонтлау

- ел дәвамында Яңа Әлем һәм Иске Әлем авылларында юлларны кардан чистарту, тигезләү

2. Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- Яңа Әлем һәм Иске Әлем авылларындагы зиратларны төзекләндерү (агач кисү һәм территорияне чистарту).

3. Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү.

4. Халыкка торак-коммуналь, көнкүреш һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә оештыру:

- Яңа Өлем һәм Иске Өлем авылларында электр челтәрен карап тоту,

- Иске Өлем авылында су челтәрләрен ремонтлау.

- Яңа Өлем, Иске Өлем авыллары су чыганакларын һәм суүткәргеч челтәрләрен лицензияләү.

5. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- җирлекнең Яңа Өлем һәм Иске Өлем авыллары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- Авыл җирлегенең ташландык участокларын чистарту, куаклар һәм агачлар кисү, объектларны сүтү һәм участокларны киртәләү

« ӘЙЕ » « ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Өлем авылы, Үзәк урамы, 27А йорт.

4. Җыенны Актаныш муниципаль районы Яңа Өлем авыл җирлеге башкарма комитеты оештырды.

5. Яңа Өлем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны халыкка игълан итәргә.

6. Үтәлешне контрольдә тотам.

Яңа Өлем авыл җирлеге башлыгы: Д.М.Әнварова